ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«03» апрель 2024 ел Яңа поселогы № 5

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге составына керүче Иске Гәрдәле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 26 октяберендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 26 октяберендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәле авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәле авылы гражданнар җыенын билгеләү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Әҗмәкәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 октябрендәге 51/2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге составына керүче Иске Гәрдәле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 26 октяберендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 27 октяберендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәле авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрелендә 16.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге составына керүче Иске Гәрдәле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 26 октяберендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юллар, тротуарлар төзү буенча эшләр башкару, юлларны ремонтлау,вак таш һәм асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре; ясалма юл тигезсезлекләрен төзү буенча эшләр башкару (ИДН һәм билгеләр алу һәм урнаштыру);;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (технологик тоташтыру, электр материаллары сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)ремонтлау;».

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 26 октяберендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәле авылыг ражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юллар, тротуарлар төзү буенча эшләр башкару, юлларны ремонтлау,вак таш һәм асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре; ясалма юл тигезсезлекләрен төзү буенча эшләр башкару (ИДН һәм билгеләр алу һәм урнаштыру);;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (технологик тоташтыру, электр материаллары сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)ремонтлау;».

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге, Иске Гәрдәле авылы, Үзәк урамы, 46А йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы Г.Т. Хөсәенова